ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИШЕЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# КАРАР

10 март 2023 ел №3

«Апас муниципаль районының Ишеево авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2013 елның 13 маендагы 5 номерлы Карарны үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Ишеево авыл җирлегенең башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Ишеево авыл җирлеге башкарма комитетының 2013 елның 13 маендагы 5 номерлы «Апас муниципаль районының Ишеево авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» карары;
- Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Ишеево авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 1 августындагы 5 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Ишеево авыл җирлеге башкарма комитеты карары;
- Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Ишеево авыл җирлеге башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 7 июнендәге 10номерлы карары.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә (бастырып чыгарырга).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Ишеево
авыл җирлеге Башлыгы Р.Р. Сатдинов